**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең Шүширмә торак пунктындагы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2020 елның 20 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 19 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта, 2020 елның 20 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта этаплап булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2021 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Шүширмә авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;
- су башнясын лицензияләү буенча түләү(коймалар урнаштыру, материал сатып алу, су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар);

авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:

- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу.

җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:

- зиратларның контейнер мәйданчыклары төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләдәрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре беркетмәсе буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 180 гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 103 кеше, бу 57 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 103 "РИЗА" позициясе өчен, 0 "КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Борындык авыл җирлегенең Шүширмә торак пунктындагы гражданнар җыенын үткән дип, нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең Шүширмә торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендәге үзара салым акчаларын 2021 елда кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;

- су башнясын лицензияләү буенча түләү(коймалар урнаштыру, материал сатып алу, су белән тәэмин итү чыганагының артскважинасын куллану өчен санитар-эпидемиологик бәяләмәне документаль рәсмиләштерү, су анализы һәм башка документлар);

авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:
- янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм техник запчастьләр сатып алу;

җирләү урыннарын карап тоту һәм ритуаль хезмәтләр оештыру:
- зиратларның контейнер мәйданчыклары төзү (материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге
Башлыгы А. Р. Гайнетдинов